КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 13 июль г.Казань № 822

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 30 май, 440 нчы карары белән расланган Объектларны дезинфекцияләү һәм йогышлы авырулар чыганакларында, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы барлыкка килү яки таралу өчен шартлар булган һәм саклана торган территорияләрдә һәм урыннарда башка санитария-эпидемиягә каршы чаралар үткәрү чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына, Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Объектларны дезинфекцияләү һәм йогышлы авырулар чыганакларында, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы барлыкка килү яки таралу өчен шартлар булган һәм саклана торган территорияләрдә һәм урыннарда башка санитария-эпидемиягә каршы чаралар үткәрү чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына, Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар

бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 30 май, 440 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 02 ноябрь, 985 нче, 2020 ел 11 декабрь, 1123 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Объектларны дезинфекцияләү һәм йогышлы авырулар чыганакларында, шул исәптән яңа коронавирус йогышлы авыруы барлыкка килү яки таралу өчен шартлар булган һәм саклана торган территорияләрдә һәм урыннарда башка санитария-эпидемиягә каршы чаралар үткәрү чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына, Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Башка бюджетара трансфертлар Министрлыкка бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.»;

9 пунктта:

беренче абзацта «Чаллы шәһәре» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетка башка бюджетара трансферт бирү турында килешүнең бертип формасын раслау хакында» 2021 елның 18 декабрендәге 17-112 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетка башка бюджетара трансферт бирү турында килешүнең бертип формасы нигезендә» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәләренең күрсәткечләре;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар турында һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән башка бюджетара трансфертлар һәм йөкләмәләр бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисапларны тапшыру формасы һәм сроклары;»;

10 пунктта:

беренче абзацта «башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» сүзләрен «башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәләре күрсәткечләре» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәләрен бәяләү килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләрен агымдагы ел тәмамлану йомгаклары буенча фактта ирешелгән башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләре белән чагыштырып карау юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты һәм Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты Министрлыкка финанслашу

максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар турында һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән башка бюджетара трансфертлар һәм йөкләмәләр бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүнең бертип формасына кушымта итеп бирелә торган формалар буенча хисап елыннан соң килүче 10 эш көненнән дә соңга калмыйча хисаплар тапшыра.»;

13 пунктның беренче абзацында «каралган күрсәткечнең мәгънәсенә ирешелмәгән» сүзләрен «каралган башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәләренең мәгънәсенә ирешелмәгән» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктның дүртенче һәм бишенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«T – башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәләренең ел ахырына фактта ирешелгән мәгънәсе;

S - килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәләренең план күрсәткечләре.»;

әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымта үз көчен югалткан дип танырга.

2. Бу карарның гамәле 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин